ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 133-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 133-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 511-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш), 2022, № 57 (I өлеш), 2024, № 56 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:
«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән затлар.»;

2) 3 статьяның 1 өлешнең 1 пунктында «35 кешедән алып» сүзләрен «36 кешедән алып» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучыларның эш белән тәэмин ителешен арттыру һәм аларны социализацияләү чаралары системасын камилләштерү максатларында әзерләнгән.

Бүгенге көнгә «Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – 60-ТРЗ номерлы Закон) социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен эш бирүчеләр тарафыннан аерым эш төрләре (һөнәрләр) резервлана дип карала.

Социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарга караган категорияләр исемлеге 2 статьяда билгеләнгән.

60-ТРЗ номерлы Закон социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар исәбенә хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарны кертә.

Әмма күрсәтелгән категория махсус хәрби операция ветераннарына караган барлык гражданнарны да колачларга мөмкинлек бирми.

Шуңа бәйле рәвештә, эшкә урнашу өчен эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен резервлауны тәэмин итү максатларында, 60-ТРЗ номерлы Законга сугышчан хәрәкәтләр ветераннарын аларга карата эшләрнең (һөнәрләрнең) аерым төрләрен эшкә урнаштыру өчен резервлау гамәлгә ашырыла торган социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар исәбенә кертүне күздә тота торган норма өстәргә тәкъдим ителә.

Моннан тыш, 3 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктның формулировкасы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы квота хезмәткәрләре саны 35 кешедән арткан эш бирүчеләргә билгеләнә дип каралган 1 өлешенә туры китерүне тәэмин итү максатларында төгәлләштерелә.

Закон проекты социаль әһәмияттәге максатка ирешүгә – сугышчан хәрәкәтләр ветераннарын эшкә урнаштыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘМӘ

«Инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм инвалидларны, социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен аерым эш төрләрен (һөнәрләрне) резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.